КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 июнь г.Казань № 667

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюдҗетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән расланган Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 июль, 524 нче; 2015 ел, 17 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 30 декабрь, 1140 нчы; 2020 ел, 15 июнь, 490 нчы; 2021 ел, 12 февраль, 73 нче; 2022 ел, 20 июнь, 591 нче; 2022 ел, 24 ноябрь, 1260 нчы; 2023 ел, 10 февраль, 127 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Сайлап алуда катнашырга планлаштырган эш бирүчеләр сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айның 1нче көненнән дә иртәрәк булмаган датага карата үбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

2.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Заявкаларны кабул итү әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән срок эчендә гамәлгә ашырыла.»;

2.8 пунктның икенче абзацында татар текстында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка кызыксынучы башкарма органнары» сүзләрен «башка кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин